**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 16 сентябрендәге 3899 номерлы карары**

**«2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. «2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. Ел саен, 2025 елдан башлап, Казан шәһәре Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле чыгымнарны раслана торган муниципаль программа кысаларында һәм чираттагы финанс елына бюджетта исәпкә алына торган акчалар чикләрендә тиешле бюджет классификациясен кулланып гамәлгә ашырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсенә (Н.Ю.Минвәлиев):

3.1. квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 20 числосына кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә әлеге карарның 2 номерлы кушымтасында китерелгән форма буенча «2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын башкару турында хисап тапшырырга;

3.2. ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук финанс чараларын кулланунын нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат тапшырырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе башлыгы Н.Ю.Минвәлиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 сентябрендәге
3899 номерлы карары
белән расланды

# МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА

«2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру»

# Муниципаль программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче (координатор) | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба − Идарә) |
| Программаны төп эшләүчеләр | Идарә |
| Программаны башкаручылар | Идарә |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты – төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу очракларын профилактикалау, кисәтү, ачыклау һәм булдырмау.<br>Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү мөһим:<br>1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.<br>2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту.<br>3. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Идарә эшчәнлеген тәэмин итү |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | Программа өч ел эчендә гамәлгә ашырылырга тиеш (2025-2027 еллар) |
| Ярдәмче программалар исемлеге | Юк |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән финанслау | Программаны финанслауның гомуми күләме 151 620,9 мең сумны тәшкил итә. |

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Казан шәһәре муниципаль бюджеты** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |

<table>
<tr>
<td>күләме</td>
<td>
<table>
<tr><td>2025</td><td>50 186,3</td><td>50 186,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>50 717,3</td><td>50 717,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>50 717,3</td><td>50 717,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>151 620,9</td><td>151 620,9</td><td>-</td></tr>
</table>
Финанслау күләме фаразлау рәвешендә бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның елларга бүленгән көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>Күздә тотылган программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>- территорияләр торышын төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренә туры китерүне;<br>- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар нормаларын бозу очраклары санын киметүне</td>
</tr>
</table>

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, төп борчыган мәсьәләләр һәм аларны хәл итү юллары

Территорияне төзекләндерү Казан шәһәренең социаль-икътисади үсешендә халыкның тормыш сыйфатына һәм дәрәҗәсенә турыдан-туры йогынты ясый торган төп юнәлешләрнең берсе булып тора. Ул территорияне карап тоту, шулай ук гражданнарның яшәү шартлары уңайлылыгын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, территориянең санитар һәм эстетик торышын саклауга һәм яхшыртуга юнәлдерелгән территорияне төзекләндерү элементларын проектлаштыру һәм урнаштыру буенча чаралар комплексын үз эченә ала.

Территорияне төзекләндерү мәсьәләләре дәүләт дәрәҗәсендә дә, җирле дәрәҗәдә дә законнар нигезендә җайга салына. Казан шәһәре территориясендә территорияне төзекләндерүгә карата таләпләр түбәндәге муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән:

- Казан шәһәре Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 28-3 номерлы «“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе” муниципаль казна учреждениесе турында»гы карары;

- Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 декабрендәге 4-11 номерлы «Казан шәһәрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» карары;

- Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 декабрендәге 7-11 номерлы «Казан шәһәрендә махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» карары;

- Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 декабрендәге 5-11 номерлы «Казан шәһәрендә муниципаль урман контроле турында нигезләмәне раслау хакында» карары;

- Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 декабрендәге 6-11 номерлы «Казан шәһәрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» карары;

- Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы «Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре турында»гы карары;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 12 декабрендәге 8023 номерлы «Казан шәһәре территориясен төзекләндерү белән бәйле җир,

төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» карары;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 4 мартындагы 1281 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрен рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны җайга сала торган нигезләмәне раслау турында»гы карары.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр Идарәгә йөкләнгән.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актларның үтәлешен муниципаль контрольдә тоту Идарәнең вазифаи затлары тарафыннан Казан шәһәре территориясендә урнашкан яки үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләргә һәм юридик затларга карата төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу очракларын ачыклау буенча тикшерүләр уздыру рәвешендә башкарыла. Идарә эшчәнлеге:

- телләр турында Татарстан Республикасы законнарын;
- җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен;
- урам, квартал эчендәге яктырту корылмаларын карап тоту кагыйдәләрен;
- тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен;
- җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне;
- яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар, спорт һәм хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чараларын урнаштыру тәртибен бозу очракларын ачыклауга юнәлдерелгән.

Программа Казан шәһәре территориясенең санитар һәм эстетик торышын саклауга һәм яхшыртуга, шәһәр халкын уңайлы яшәү шартлары белән тәэмин итүгә һәм Татарстан Республикасы башкаласының тышкы җәлеп итүчәнлеге дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән.

## II. Программаның максаты, бурычлары, төп чаралары, көтелгән ахыргы нәтиҗәләренең тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары

Программаның максаты – төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу очракларын профилактикалау, кисәтү, ачыклау һәм булдырмау.

Күрсәтелгән максатка ирешү өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү мөһим:

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту;

- үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Идарә эшчәнлеген тәэмин итү.

Бурычларны хәл итү өчен түбәндәге чаралар планлаштырылган:

- планнан тыш контроль чаралар үткәрү;

- физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан кылынган административ хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау;

- хезмәткәрләрне һөнәри яктан укыту.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына финанслана. Финанслауның гомуми күләме 151 620,9 мең сумны тәшкил итә

| **Ел** | **Акча күләме, мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|
| | **Барлыгы** | **Казан шәһәре муниципаль бюджеты** | **Бюджеттан тыш чыганаклар** |
| 2025 | 50 186,3 | 50 186,3 | - |
| 2026 | 50 717,3 | 50 717,3 | - |
| 2027 | 50 717,3 | 50 717,3 | - |
| **БАРЛЫГЫ** | **151 620,9** | **151 620,9** | **-** |

Финанслау күләме фаразлау рәвешендә бирелә һәм аңа, тиешле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Финанслауның башка чыганаклары гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнергә мөмкин.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль планнан тыш тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр үткәрү тәртибе Казан шәһәр Думасының 2021 елның 16 декабрендәге 4-11 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмә белән билгеләнгән.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актларның үтәлеше предметына территорияләрне мониторинглау Идарәнең вазифаи затлары тарафыннан Казан шәһәре территориясен йөреп чыгу рәвешендә үткәрелә. Төзекләндерү кагыйдәләрен бозуның ачыкланган очраклары Идарә хезмәткәрләре тарафыннан административ хокук бозу турындагы беркетмәдә теркәлә. Яшел территорияләрдә, балалар, спорт һәм хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чараларын урнаштыру тәртибен бозулар махсус техник чаралар ярдәмендә теркәлә.

Гамәлгә ашыруның барлык этапларын исәпкә алып, Программаны үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту Идарә хезмәткәрләре тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының башка структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм федераль хакимият органнары белән тыгыз бәйләнештә һәм мәгълүмат алмашу юлы белән башкарыла.

## V. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән социаль-икътисади нәтиҗә төгәл күләмдә бәяләнә алмый, чөнки Программа һәрберсе билгеле бер уңай нәтиҗәгә ирешү юлы белән гамәлгә ашырыла торган чараларны үз эченә ала.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген муниципаль заказ бирүче бәяли. Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге, Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше планлаштырылган чыгымнар дәрәҗәсенә туры килгәндә, максатчан индикаторларның һәм күрсәткечләрнең фактта ирешелгән зурлыкларын һәм аларның пландагы зурлыкларын чагыштыру юлы белән Программаның максатына һәм бурычларына ирешү дәрәҗәсеннән чыгып бәяләнә (кушымта).

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар нормаларын бозу очраклары санын киметү һәм территорияләр торышын төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренә туры китерү планлаштырыла.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 сентябрендәге
3899 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(Форма)

**«2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын башкару турында 20___ елның __________ өчен хисап**

| № т/б | Бүлек, чара исеме | Финанслау чыганагы | Программаны раслау турындагы норматив хокукый акттан хисап елына планлаштырылган финанслау күләме, мең сум | Программа буенча хисап чорына бүлеп бирелгән (лимит), мең сум | Финанслау проценты | Ел башыннан фактта тотылган акча (башкаручы счетыннан күчерелгән), мең сум | Индикатор атамасы, үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Узган ел | | Агымдагы ел | | | Киләсе елга план |
| | | | | | | | | План | Факт | План | Факт | Башкару проценты | |
| Программа буенча барлыгы | | Барлыгы | | | | | | | | | | | |
| | | Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |
| | Казан шәһәре бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | | | | | | |

«2025-2027 елларга Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына кушымта
(Форма)

## Программаның максаты, бурычлары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, программа чаралары буенча финанслау

| Бурычның атамасы | Төп чараларның атамалары | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Чыганагын күрсәтеп финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 база елы | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Максат: төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен бозу очракларын профилактикалау, кисәтү, ачыклау һәм булдырмау | | | | | | | | | | | |
| 1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру | Планнан тыш контроль чаралар үткәрү | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2025-2027 еллар | Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозу очракларын бетерү турында суд тәртибендә дәгъваланган күрсәтмәләр саны, данә | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| 2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру | Физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан кылынган административ хокук бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» | 2025-2027 еллар | Алар буенча чаралар күрелгән гражданнар мөрәҗәгатьләре һәм Казан шәһәрен төзекләндерү өлкәсендә муниципаль | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| Бурычның атамасы | Төп чараларның атамалары | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Чыганагын күрсәтеп финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 база елы | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| | | муниципаль казна учреждениесе | | норматив хокукый актларның мәҗбүри таләпләрен бозу очраклары өлеше, % | | | | | | | |
| 3. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча Идарә эшчәнлеген тәэмин итү | Хезмәткәрләрне һөнәри яктан укыту | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе | 2025-2027 еллар | Өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча квалификациясен күтәргән хезмәткәрләр саны, кеше | 17 | 17 | 17 | 17 | | | |
| **Программа буенча БАРЛЫГЫ – 151 620,9 мең сум** | | | | | | | | | **50 186,3** | **50 717,3** | **50 717,3** |